**З.Н.Ки риллова**
**Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан**

# ТАТАР ҺӘМ КӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ ТӨРКИ ТЕЛЛӘРДӘ ИЯРТҮЧЕ ТЕРКӘГЕЧЛӘРНЕҢ КУШМА ҖӨМЛӘ ТӨЗҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена сравнительному исследованию подчинительных союзов в татарском и юго-западных тюркских языках, выявлению особенностей образования данными союзами различных типов придаточных предложений.

Ключевые слова: татарский язык, юго-западные тюркские языки, подчинительный союз, сложноподчиненное предложение, придаточное предложение.

This article is devoted comparative research of subordinating conjunctions in Tatar and southwest Turkic languages, to revealing of features of formation by the given unions of various types of subordinate clauses.

Key words: the Tatar language, southwest Turkic languages, subordinating conjunction, compound sentence, subordinate clause.

Күренекле тюркологлар Н.А.Баскаков, А.Н.Самойлович һ.б. классификацияләре буенча, төрки телләрнең кыпчак, яки төньяк-көнчыгыш, В.А.Богородицкий бүленешендә исә Идел-Урал буе төркеменә кертелгән татар теле һәм угыз, яки көньяк-көнбатыш төркемгә караган төрек, азәрбайҗан, гагауз һәм төрекмән телләре [2: 114-122] уртак ияртүче теркәгечләргә ия: ки, чөнки, әгәр, гәрчә, гүя. XX гасыр башына кадәр исә бу исемлек тулырак булган: чүн // чөн, чөнкем, зира/зирә, мадам ки, гәр, әгәрчә, санки һ.б. Әлеге теркәгечләрнең хәзерге көньяк-көнбатыш төрки телләрдәге урынына мөрәҗәгать итик.

Алда саналган ияртүче теркәгечләр Н.А.Баскаков тарафыннан угыз-сәлҗүк төркемчәсенә кертелгән төрек һәм азәрбайҗан телләрендә аеруча күп күзәтелә. Мәсәлән, төрек телендә дә, азәрбайҗан телендә дә ки, чүнкү, зира, әгәр, гәрчи, мадәмки, гүя, санки теркәгечләре кулланыла. Бигрәк тә **ки** теркәгече әлеге телләрдә гаять дәрәҗәдә активлыгы белән аерылып тора һәм

барлык иярчен җөмлә төрләрен дә диярлек баш җөмләгә бәйләүдә катнаша. А.Н.Кононов күрсәткәнчә, төрек телендә ул керешмә җөмләләрдә дә, аерымланган кисәкләрдә дә, хәтта модаль сүз функциясендә дә кулланыла [8: 546].

Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи синтаксисында һәм Н.З.Гаджиева хезмәтләрендә "көньяк төрки телләр тарихында **чүн** теркәгече иярчен вакыт, сәбәп һәм шарт җөмләләрне формалаштыруда катнашкан, хәзерге вакытта исә ул сәбәп мәгънәсен генә белдерүгә күчкән" [5: 215-216; 3: 365; 4: 69-72], – диеп күрсәтелә, әмма хәзерге көньяк телләрнең грамматикаларында әлеге теркәгеч хакында бернинди мәгълүмат та урын алмый. Чүн һәм ки теркәгечләре кушылып ясалган **чүнки** бәйләүче чарасы исә барлык телләрдә дә бик актив һәм хәзерге вакытта сәбәп мәгънәсен белдерү өчен хезмәт итә.

Азәрбайҗан, төрек һәм төрекмән язма истәлекләрендә табылган чүнким теркәгече, грамматикалардан күренгәнчә, хәзерге вакытта кулланылмый. Татар телендә дә аның аналогы булган **чөнкем** бары Г.Тукайда гына күзәтелде: *Нәрсәдә ләззәт икән? Чөнкем ялан дөньяда кәм – Мин ләзиз шәйләр, вә ли кайсында ләззәт, кайда тәм? (Чөнки азмыни ләззәтле нәрсәләр, ләкин аларның кайсында ләззәт тә кайсында тәм? – З.К.).*

Азәрбайҗан, төрек һәм гагауз телләрендә, сәбәп мөнәсәбәтен белдерү өчен, фарсы чыгышлы **зира** теркәгече дә урын ала, ул җөмләләрне бәйләүдә үзе генә яки ки теркәгече белән катнаша: *Buna inaniyorum, zira Ali bey gibi kendisine guvenilir zat da bahsetmisti – Мин моңа ышанам, чөнки моны Али бәй кебек үз-үзенә ышанган кеше сөйләде* [1: 170]. Тик шунысы игътибарга лаек: төрек һәм азәрбайҗан грамматикаларында зира теркәгеченең кулланылыш ешлыгы кимү, аның күбрәк чүнкү теркәгече белән алыштырылуы хакында да әйтелә [8: 546; 1: 155; 6: 175].

Гарәп чыгышлы һәм "чөнки, әгәр шулай икән, чынлыкта" мәгънәләрен белдерүче **мадам ки** теркәгече азәрбайҗан, төрек һәм үзбәк телләрендә үтәлгән шарт мәгънәсендәге иярчен җөмләләрне барлыкка китерә, моннан тыш, хәзерге

үзбәк телендә ул мадами ки рәвешендә иярчен шарт, аергыч, ия һәм кире шарт җөмлә төрләрен хасил итә ала. Азәрбайҗан теленнән мисал: *Мадам ки өзү разыдыр, даһа мән нә дейә биләрәм. – Ул үзе риза булган икән, мин тагын нәрсә әйтә алам?* [6: 176]. Мадәмки белән чагыштырганда сирәгрәк булса да, мадам теркәгече дә урын ала. Мәсәлән, төрек теленнән мисал: *Madam gormek istiyorsunuz, gelin, gorun! – Әгәр күрергә теләсәгез, килегез, күрегез!* [8: 360].

Шарт мәгънәсен белдерүче теркәгечләр арасында **әгәр** теркәгече гаять зур урын били. Төрле төрки телләрдә егер // эгер // әкәр // кәр формаларында кулланыла торган фарсы чыгышлы әлеге теркәгечнең **гәр** варианты бары шагыйрьләр иҗатында гына табылды, һәм бу кыскарту шигъри юлларның ритм һәм рифма бөтенлеген саклау максатында барлыкка килергә мөмкин: *Канча тартсаң, и мөхәррир, сүзне чит тел сибенә (уңаена, ибенә - З.К.) Тел ясалмас, гәр туган сүз ятмаса үз ибенә!* (Дәрдмәнд). *Иртәгә килгәнче дустлар тәндә җаным торса гәр, Шул фәлән атлы кеше кысты диермен сорсалар* (Г.Тукай). Әлеге мисаллардан күренгәнчә, гәр теркәгече, хәзерге телдәге әгәр теркәгече кебек үк, иярчен җөмләнең шарт фигыль формасындагы хәбәре белән берлектә кулланылып, өстәмә роль генә үтәп килә.

Кире шарт мәгънәсен белдерү өчен, ияртүче теркәгечләрдән **гәрчә** бәйләүче чарасы кулланыла. Күренекле тюрколог Н.З.Гаджиева фикере буенча, әгәр сүзеннән ясалган егерчи // герчи // герче теркәгечләре азәрбайҗан, төрек, төрекмән телләрендә һәм аларның язма истәлекләрендә очрый. Төрек теленнән бер мисал: *Gerci simdiye kadar gorusemedik, lakin giyaben size tanyordum. – Хәзергә кадәр күрешмәсәк тә, мин сезне читтән торып белә идем* [1: 168]. Татар әдәби әсәрләрендә исә бу теркәгечкә мисаллар аз очрады, мәсәлән, Дәрдмәнд шигырьләрендә күзәтелде: *Ишәк, мескен, әгәрчә битәмиздер (пакь, чиста түгел – З.К.), Авыр йөк ташыган өчен газиздер! Әгәрчә дәүләтем юктыр җитәрлек, Ишәктәй һәм йөк астында түгелмен.* Әлеге мисаллардан күренгәнчә, хәзерге телдәге гәрчә теркәгеченнән аермалы буларак, әгәрчә

бәйләүче чарасы шарт фигыль кушымчасы һәм да/дә кисәкчәләре белән кулланылмый, нәтиҗәдә аналитик иярчен кире җөмлә ясауда төп рольне үти.

Санки теркәгече көньяк-көнбатыш төрки телләрдә, шулай ук кумык телендә чагыштыру мәгънәсен белдергән иярчен җөмләләр төзүдә катнаша [3: 363]: *О элә күлдү ки, санки полад чинкилдәди. – Ул шулай көлде ки, гүя тимер чыңлады* [11: 269]. Татар телендә табылган мисаллардан Г.Тукай үзенең шигырьләрендә һәм Дәрдмәнд истәлек-парчаларында охшату-чагыштыру мәгънәсен санки теркәгече ярдәмендә белдерәләр: *Бар күңел хәдсез (чиксез), хисапсыз мәрхәмәт, шәфкать тулы, Санки күңлең җиргә күктән иңгүче рәхмәт юлы* (Г.Тукай). “Хәят” шигырендә исә Дәрдмәнд санкем теркәгеченә өстенлек бирә: *Санкем угыл-кыз туен итмәктә ул, кызган уен, Йөгрешеп, курчак төшеп менмәктә ак бармагына* (Дәрдмәнд). Күренгәнчә, санки һәм санкем теркәгечләре, иярчен рәвеш җөмлә хасил итеп, аның башында да, уртасында да килергә мөмкиннәр.

Н.А.Баскаков классификациясе буенча, угыз-төрекмән төркемчәсенә кертеп тикшерелгән төрекмән теле ияртүче теркәгечләрнең аз кулланылуы белән аерылып тора. Мәсәлән, төрекмән теле грамматикасында эгер һәм чүнки теркәгечләре генә китерелә, ки // ким теркәгеченең дә XVIII-XIX гасыр әдәбиятында урын алуы, әмма хәзерге әдәби телдә кулланылмавы билгеләнә [7: 444].

Угыз-болгар төркемчәсенә кергән гагауз теле исә, киресенчә, башка төрки телләрдән ияртүче теркәгечләрнең күп урын алуы белән аерылып тора һәм моның белән рус теленең синтаксик төзелешенә якынлык күрсәтә [9: 277]. Соңгы ике гасыр дәвамында башка төрки халыклар белән бәйләнешкә кермәгән һәм болгар, молдаван, рус һәм украиннар чолганышында яшәгән гагаузларның телләрендә дә әлеге халыкларның йогынтысында үзгәрешләр барлыкка килә. Гагауз теле белгечләре күрсәтүенчә, бу телдә башка угыз телләре белән уртак теркәгечләр аз, булганнарына да үзенчәлекле кулланылу хас. Мәсәлән, фарсы чыгышлы ки, чүнкү, зерә // зерем, еер // хер теркәгечләре әкренләп башка

сүзләр белән алыштырыла: ки – ани, чүнкү – нечинки, зерә сәбәп теркәгеченнән тезүче теркәгечкә әверелеп бара һ.б. [10: 145-146]. Ки теркәгече, башка төрки телләрдән аермалы буларак, иярчен җөмлә башында урын ала: *Вар о түрлү да инсаннар, ки азетмеерлар чок ишлемәә. – Шундый кешеләр дә бар ки: күп эшләргә яратмыйлар* [10: 151].

Йомгак ясап әйткәндә, хәзерге татар телендә көньяк-көнбатыш төрки телләр белән уртак ияртүче теркәгечләр берничә: ки, чөнки, әгәр, гәрчә, гүя. XX гасыр башына кадәрге татар әдәби телендә урын алган чөн, чөнкем, зира, санки, мадамки һ.б. теркәгечләр исә беренче чиратта угыз-сәлҗүк төркемчәсенә кертеп каралган төрек һәм азәрбайҗан телләре өчен хас. Шул ук вакытта әлеге телләрдә дә хәзерге вакытта чүн, мадамки, зира теркәгечләренең аз кулланылуы күзәтелә. Төрекмән теле теркәгечләрнең гаять аз урын алуы белән аерылып тора, ә гагауз телендә исә теркәгечләр үзенчәлекле кулланылышка ия.

Әдәбият


1. Баскаков А.Н. Предложение в современном турецком языке / А.Н.Баскаков. – М.: Наука, 1984. – 200 с.
2. Баскаков Н.А. Очерки истории функционального развития тюркских языков и их классификация / Н.А.Баскаков. – Ашхабад: Ылым, 1988. – 140 с.
3. Гаджиева Н.З. Основные пути развития синтаксической структуры тюркских языков / Н.З.Гаджиева. – М.: Наука, 1973. – 408 с.
4. Гаджиева Н.З. Синтаксис сложноподчиненного предложения в азербайджанском языке (в историческом освещении) / Н.З.Гаджиева. – М.: Изд-во АН СССР, 1963. – 220 с.
5. Гаджиева Н.З. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Синтаксис / Н.З.Гаджиева, Б.А.Серебренников. – М.: Наука, 1986. – 284 с.

6. Грамматика азербайджанского языка (Фонетика, морфология и синтаксис) / Под ред. М.Ш.Ширалиева и Э.В.Севортяна. – Баку: Изд-во “Элм”, 1971. – 413 с.

7. Грамматика туркменского языка. Ч. I. Фонетика и морфология / Под ред. Н.А.Баскакова, М.Я.Хамзаева, Б.Чарыярова. – Ашхабад: Ылым, 1970. – 503 с.

8. Кононов А.Н. Грамматика современного турецкого литературного языка / А.Н.Кононов. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1956. – 569 с.

9. Покровская Л.А. Грамматика гагаузского языка. Фонетика и морфология. – М.: Наука, 1964. – 298 с.

10. Покровская Л.А. Синтаксис гагаузского языка в сравнительном освещении / Л.А.Покровская. – М.: Наука, 1978. – 203 с.

11. Сравнительная грамматика русского и азербайджанского языков / Под ред. М.А.Ширалиева и С.А.Джафарова. – Баку: Изд-во АГУ им. С.М.Кирова, 1954. – 397 с.